КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 23 ноябрь г.Казань № 1111

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру буенча төбәк программасын раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1265 нче карары белән расланган 2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру буенча төбәк программасын раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру буенча төбәк программасын раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1265 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 24 ноябрь, 1056 нчы карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) расланган 2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру буенча төбәк программасына, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә 2022 елның 1 мартына кадәр 2021 елга Татарстан Республикасын газлаштыру

чаралары планы үтәлеше турындагы хисапны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы адресына кертүне тәкъдим итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин